КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 июль г.Казань № 661

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2018 ел, 29 март, 185 нче; 2018 ел, 4 май, 317 нче; 2018 ел, 27 июнь, 523 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1140 нчы; 2019 ел, 16 гыйнвар, 9 нчы; 2019 ел, 4 апрель, 270 нче; 2019 ел, 29 сентябрь, 860 нчы; 2020 ел, 26 март, 220 нче; 2020 ел, 25 май, 424 нче; 2020 ел, 26 август, 744 нче; 2020 ел, 14 октябрь, 924 нче; 2021 ел, 4 май, 306 нчы; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче, 2022 ел, 5 март, 196 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә, 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап бирә:

табигать ресурсларыннан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү (01.06), шул исәптән:

атмосфера һавасын саклау өлкәсендә идарә итү (01.06.06);

радиация куркынычсызлыгын тәэмин итү (01.06.08);

үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасында радиация торышын контрольдә тоту (01.06.16);

җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләре өлкәсендә җайга салу (01.06.01), шул исәптән:

файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итү яки техник су белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб метрдан артмаган гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасын үткәрүне оештыру (01.06.15);

Татарстан Республикасы территориясендә геологик разведка һәм геодезия эшчәнлеге белән идарә итү (03.01.09);

төбәк дәүләт геологик контроле (күзәтчелеге) (01.06.19);

Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) (01.06.11).».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 22 сентябрь, 895 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1370 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1.3. Төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелек) Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында калдыклар белән өлкәсендә территориаль схеманы раслау турында» 2018 ел, 13 март, 149 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 14 май, 391 нче; 2020 ел, 21 май, 414 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында калдыклар белән өлкәсендә территориаль схемага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

2.2 бүлекчәдәге 2.2.1 нче таблицадан соң бишенче абзацта «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 бүлекчәнең 2.5.1 нче таблицасында:

исемендә «күзәтчелегендә» сүзен «контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга.

«Федераль дәүләт экология күзәтчелеге» юлында «күзәтчелеге» сүзен «контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

«Төбәк дәүләт экология күзәтчелеге» юлында «күзәтчелеге» сүзен «контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

2.8 пунктның дүртенче абзацында «күзәтчелеген» сүзен «контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга;

9 бүлектә:

9.1.11 бүлекчәнең дүртенче абзацында «күзәтчелегендә» сүзен «контролендә (күзәтчелегендә)» сүзләренә алмаштырырга;

9.6 бүлекчәнең тугызынчы абзацында «күзәтчелегендәге» сүзен «контролендәге (күзәтчелегендәге)» сүзләренә алмаштырырга;

11 бүлектә:

3 пунктның икенче абзацында «экология күзәтчелеген» сүзләрен «дәүләт экология контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкә һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендә стратегияне раслау турында» 2021 ел, 18 август, 748 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 4 июнь, 520 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкә һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендә стратегиягә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.12 пунктта:

3 пунктчада «төбәк дәүләт экология күзәтчелеге» сүзләрен «төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктчада «дәүләт экология күзәтчелеге» сүзләрен «төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлектәге таблицаның 12 бүлегендәге 2 пунктның 3 графасында «дәүләт экология күзәтчелеге» сүзләрен «төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

6 бүлектәге таблицаның 12 бүлегендә:

3 пунктның 2 графасында «дәүләт экология күзәтчелеге» сүзләрен «төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның 3 графасында «дәүләт экология күзәтчелеге» сүзләрен «төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

7 бүлектәге таблицаның 12 бүлегендә:

3 пунктның 2 графасында «дәүләт экология күзәтчелеге» сүзләрен «төбәк дәүләт экология контроле (күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның 4 графасында «дәүләт күзәтчелеген» сүзләрен «төбәк дәүләт экология контролен (күзәтчелеген)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры | А.В.Песошин